| ГЛАВА СОВЕТА ХОЗЕСАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 ноябрь, 2020 ел Хуҗа Хәсән авылы № 5

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл
җирлегенең Турминский торак пунктында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2020 елның 20 ноябренә 14 сәг 00 минутка Турминский ав.,. Үзәк ур, 6 йорт адресы буенча урнашкан Турминский авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Турминский торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***беренче этабын*** билгеләргә.

2. 2020 елның 23 ноябренә 11 сәг 00 минутка Турминский ав.,. Үзәк ур, 6 йорт адресы буенча урнашкан Турминский авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Турминский торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***икенче этабын*** билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны урыны буенча Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Турминский авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне

хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

-җирлекнең торак пунктлары чүплекләре территорияләрен чистарту;

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту»

« РИЗА» «КАРШЫ»

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.




Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башлыгы С.П.Матвеева